| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |
| **ПРИКАЗ**<br>15.12.2020 | Казан ш. | **БОЕРЫК**<br>1397-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфраклар сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 10 июлендәге 382-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфраклар сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 10 июлендәге 382-п номерлы боерыгына (Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 22 октябрендәге 617-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 пунктта «туфраклар сыйфатына» сүзләреннән алда «әлеге боерыкка кушымта нигезендә» сүзләрен өстәргә;

2. 2 пунктта «Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе» сүзләрен «Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм экологик мониторинг идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

3. Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфракларның сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибендә:

5 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында туфракларның сыйфатының төбәк нормативлары проектларын карау өчен Министрлыкның җаваплы бүлекчәсе булып Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм экологик мониторинг идарәсе (алга таба – Идарә) тора.

Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләренә туры килү-килмәве мәсьәләләре буенча туфракларның

сыйфатының төбәк нормативлары проектларын карау срогы 21 эш көненнән дә артмый.

Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләренә туры килмәү очраклары ачыкланган очракта, Министрлык тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә нигезле баш тарту турында хат җибәрелә.

Баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.»;

7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Туфраклар сыйфатының төбәк нормативлары проектының федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләренә туры килүе очрагында, әлеге төбәк нормативлары Министрлык боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә раслана һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә кертелә.»;

9 пунктта «Дәүләт экология экспертизачы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе» сүзләрен «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 13 февралендәге 149 номерлы карары белән расланган Әйләнә-тирә мохит торышының химик һәм физик күрсәткечләре өчен әйләнә-тирә мохит сыйфаты нормативларын эшләү, билгеләү һәм яңадан карау турындагы нигезләмәнең 29 пунктын үтәү йөзеннән, Министрлык, 14 календарь көненнән артмаган срокта, туфраклар сыйфатының төбәк нормативларын һәм, аларны системалаштыру максатларында, электрон чыганакта нигезләү материалларын электрон рәвештә Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгына җибәрә».

Министр А.В. Шадриков